КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 1 март г.Казань № 189

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өстәмә һөнәри белем бирүгә дәүләт мәгариф сертификатлары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен укытуны оештыру һәм финанслар белән тәэмин итү турында» 2021 ел, 15 сентябрь, 872 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өстәмә һөнәри белем бирүгә дәүләт мәгариф сертификатлары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен укытуны оештыру һәм финанслар белән тәэмин итү турында» 2021 ел, 15 сентябрь, 872 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Өстәмә һөнәри белем бирүгә дәүләт мәгариф сертификатлары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен укытуны оештыру тәртибе турындагы нигезләмәдә:

3 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үзгәртеп оештыру (мәгариф оешмасына башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмаска, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәскә, мәгариф оешмасының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаска тиеш;»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 процenttан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

әлеге карар белән расланган Өстәмә һөнәри белем бирүгә дәүләт мәгариф сертификатлары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен укытуга бәйле чыгымнарны каплау максатларында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү кагыйдәләрендә:

1.3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Грант турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

2.1 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 процenttан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында

офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый.»;

2.5 пунктта:

бишенче абзацта «өченче – җиденче» сүзләрен «өченче – сигезенче» сүзләренә алмаштырырга;

ундүртенче абзацта «вәкаләтле орган» сүзләрен «Министрлык» сүзенә алмаштырырга;

2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Министрлык, сайлап алу башлану датасына кадәр биш календарь көннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм үзенең рәсми сайтында (https://mon.tatarstan.ru/), түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Кагыйдәләрнең 2.18 пункты нигезендә грант бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 2.2 пункты нигезендә мәгариф оешмаларына карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен мәгариф оешмалары тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 2.5 пункты нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Кагыйдәләрнең 2.7 – 2.9 пунктлары нигезендә заявкаларны карау кагыйдәләрен;

мәгариф оешмаларына сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләрен аңлату тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан грант бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) куелырга тиешле имза кую срогын;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе бюджет системасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бердәм порталында һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасын.»;

2.7 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Заявка почта элемтәсе оешмасы аша кергәндә заявканы теркәү датасы булып почта аша җибәрелгән хатларны турыдан-туры Министрлыкка тапшыруны гамәлгә ашыручы почта элемтәсе оешмасының структур бүлекчәсе тарафыннан почта аша җибәрелгән хатны алу датасы һәм вакыты санала. Министрлык адресына килгән заявка почта аша җибәрелгән хатка почта элемтәсе оешмасының тиешле структур бүлекчәсе штемпеле сугылып расланган булырга тиеш.»;

өченче абзацта «вәкаләтле органга» сүзләрен «Министрлыкка» сүзенә алмаштырырга;

2.12 пунктның икенче абзацында «Россия Федерациясе Пенсия фондына, Россия Федерациясе Социаль иминият фондына» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына» сүзләренә алмаштырырга;

2.16 пунктта:

бишенче абзацта татар текстында «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«грант бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

тугызынчы абзацта «максатын,» сүзен төшереп калдырырга;

унберенче абзацта «вәкаләтле органга» сүзләрен «Министрлыкка» сүзенә алмаштырырга;

бишенче абзацта татар текстында «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга;

IV бүлекнең исемендә «, максатының» сүзен төшереп калдырырга;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Министрлык грант алучының грант бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән грант бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне башкара.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^{1}$ һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

Грант бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау, килешүдә билгеләнгән грант бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешүдән һәм грант бирү нәтиҗәләрен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.»;

4.4 пунктта «, максаты» сүзен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин